ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25.05.2026** **Зеленодольск** **№ 1841**

Реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтадагыча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының .2021 елның 26 августындагы « Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» 2091 номерлы карары; Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының « Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 августындагы «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» 2091 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2128 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Республики Татарстан
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2026 елның
25 маендагы 1841 номерлы
карарына
кушымта

**Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен (алга таба – муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләр мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) яклый ала.

1.3. Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүчегә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә бирелергә тиеш (алга таба - Бердәм портал).

Мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына карамастан ,Бердәм һәм региональ порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында хезмәт күрсәтү барышы турында статуслар һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе урнаштырыла.

## 2. Хезмәт күрсәтү стандарты

Хезмәт күрсәтү атамасы

Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару

2.2. Хезмәтне күрсәтүче органның аталышы

Хезмәт Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Мөрәҗәгать итүче «Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирүне» сорап мөрәҗәгать иткәндә хезмәт нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт (5 нче кушымта).

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (7 нче кушымта);

2.3.2. Мөрәҗәгать итүче «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару»ны сорап мөрәҗәгать иткәндә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару турында карар (6 нчы кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (7 нче кушымта).

2.3.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе 2011 елның 6 апрелендәге «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Республика порталындагы шәхси кабинетына Башкарма комитетының вазифаи затының (яки Башкарма каомитетның) көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ нөсхәсе рәвешендә КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган кәгазь саклагычта КФҮтә алырга мөмкин.

2.3.5. Мөрәҗәгать итүче хезмәт нәтиҗәсен хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында электрон документ рәвешендә яки кәгазь саклагычта электрон документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

## 2.4. Хезмәт күрсәтү срогы

11. Республика порталы аша Башкарма комитетка, КФҮ мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) карамастан, хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 12 эш көне тәшкил итә.

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт биргәндә хезмәт күрсәтү срогы 12 эш көне тәшкил итә;

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт гамәлдән чыгарылганда хезмәт күрсәтү срогы 7 эш көненнән дә артмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгән көннән соң килә торган көннән исәпләнә башлый.

2.4.2. Хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң, икенче көннән исәпләнә башлый.

2.4.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ рәвешендә җибәрү хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә башкарыла.

## 2.5. Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.5.1. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында карар Башкарма комитет тарафыннан түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

1) Регламентка 4 нче кушымтада билгеләнгән тулы булмаган документлар комплектын тапшыру;

2) ведомствоара мәгълүмати бәйләнеш кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турында белешмәләр расланмау, мөрәҗәгать итүче исеменнән гариза (рәсми мөрәҗәгать) моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр, килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зарарланулар булган документларны, үз көчен югалткан документларны тапшыру;

5) Регламент нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне алучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри юлларны корректлы тутырмау, электрон формада һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу;

7) электрон рәвештәге гаризага (рәсми мөрәҗәгатькә) һәм башка документларга электрон имза гамәлдәге законнарны бозып куелган;

8) электрон документларның тапшыру форматларына куелган таләпләргә туры килмәве һәм (яисә) укылмавы.

9) реклама конструкциясен урнаштыруның күздә тотылган урынында реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә гамәлдәге рөхсәт булу.

2.5.2. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.5.3. «Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү» хезмәтен бирүдән баш тарту турындагы карар Башкарма комитет тарафыннан түбәндәге нигезләрдә кабул ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен документның булмавы һәм (яисә) кирәкле мәгълүматның булмавы турында дәлилли торган ведомствоара рәсми мөрәҗәгатькә дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимиятенең ведомство буйсынуындагы органының яисә оешманың җирле үзидарә органының җавабы килү;

Реклама корылмасын урнаштыру һәм аннан файдалану өчен күпфатирлы йорттагы фатир хуҗаларының утрак мөлкәттән файдалану күздә тотылган очракта, күпфатирлы йорттагы фатир хуҗаларының гомуми санының өчтән ике өлеше риза булмау;

3) хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү факты расланмаган;

4) реклама конструкциясе проектының техник регламент таләпләренә туры килмәве;

5) реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы куелган урында реклама конструкциясе җайланмасының туры килмәве (38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.8 өлеше нигезендә реклама конструкциясе урнаштыру урыны реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы билгеләнә торган очракта);

6) транспорт хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча норматив актлар таләпләрен бозу;

7) җирлекнең яисә шәһәр округының төзелешенең тышкы архитектура күренеше бозылу. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары яки шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яисә аның территориясенең бер өлешендә урнаштыру рөхсәт ителә торган һәм рөхсәт ителми торган реклама конструкцияләренең типларын һәм төрләрен, шул исәптән мондый реклама конструкцияләренә карата таләпләрне, барлыкка килгән җирлекләрнең яисә шәһәр округларының төзелешенең тышкы архитектура йөзен саклап калу кирәклеген исәпкә алып билгеләргә хокуклы;

8) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу, аларны саклау һәм алардан файдалану;

реклама корылмасын урнаштыру һәм аннан файдалану өчен күпфатирлы йорттагы фатир хуҗаларының гомуми милке кулланылган очракта, 38-ФЗ номерлы федераль законның 19 статьясында 5 өлешендәге 5.1, 5.6, 5.7 өлешләре белән билгеләнгән таләпләр бозылганда.

2.5.4. «Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү» хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару өчен мөрәҗәгать иткәндә, мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамлануы;

2) мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризаны кире алу.

Хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

2.6.1. Дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясындагя 1 өлешенең 105 пунктында түбәндәге күләмдә каралган:

реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәт биргән өчен - 5000 сум;

Дәүләт пошлинасы мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза биргәнче түләнә.

2.6.2. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча хезмәт бушлай күрсәтелә.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан хезмәт күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү, алдан тутырылган реквизитлар буенча , Республика порталыннан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә мөрәҗәгать итүчегә тутырылган яисә өлешчә тутырылган түләү документын, шулай ук тутырылган түләү документының бастырылган кәгазь саклагычтагы күчермәсен саклап калу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Түләү документында исәпләүнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчегә Республика порталы аша хезмәт күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы факты турында хәбәр ителә.

20. Башкарма комитетның мөрәҗәгать итүчедән хезмәтләр күрсәтү өчен түләүне керткәнне раслый торган документлар бирүне таләп итәргә хокукы юк.

Хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы мәгълүматны бирү, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматтан файдаланып гамәлгә ашырыла.

2.6.5. Хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү күләме турындагы мәгълүмат Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

2.7.1. Хезмәт күрсәтү өчен гариза биргәндә көтү вакыты – иң күбе 15 минут.

2.7.2. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.

2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы

Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә гариза тапшырылган көнне күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелгүен раслый торган теркәү номеры һәм гариза бирүнең датасы күрсәтелгән раслама бирелә.

Гариза Республика порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслый торган, гаризаны теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

Гаризаны ике нөсхәдә тапшырган көнне шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Органның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә, гаризаны кабул итү датасын һәм аңа теркәп бирелгән документларны күрсәтеп, бер нөсхәсе кире кайтарыла.

## 2.9. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

23. Хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

2.9.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

Хезмәт күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керү (бүлмәгә керү-бүлмәдән чыгу урыннарының һәм бүлмә эчендә йөрүнең уңайлы булу) мөмкинлеге .

2) Хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган инвалидларны йөртү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат такталарын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетеп һәм күреп була торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне, башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтын кулланып башкарылган билгеләр белән кабатлап бирү;

5) сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

8) йөртүче этне махсус өйрәтелүен раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документы булганда, йөртүче этне бинага кертергә рөхсәт итү.

25. Хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм Хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, Регламентның 23 пунктының 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгәнчә, 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация, реконструкция үткәрелгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.9.4. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында, КФҮдә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

## 2.10. Хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре

2.10.1. Хезмәтне күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

документлар кабул ителә һәм бирелә торган биналарның җәмәгать транспортына якын урында урнашуы;

кирәкле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуда комачаулый торган киртәләрне узуда ярдәм итү.

2.10.2. Хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срогын үтәү;

2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән аралашуы гариза белән барлык кирәкле документларны биргәндә бер тапкыр башкарыла;

4.2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазь нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән бер тапкыр аралашу озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм портал, Республика порталы, терминал җайланмаларын кулланып бәяләргә хокуклы.

2.10.3. Хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Бердәм порталдагы яки Республика порталындагы шәхси кабинеты аша, күпфункцияле үзәктә алырга мөмкин.

2.10.4 Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮ үзенең яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтүне комплексլы рәсми мөрәҗәгать составында алырга хокуклы.

2.10.6. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында, КФҮдә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

2.10.7. Хезмәт алдан (проактив) тәртиптә күрсәтү күздә тотылмаган.

## 2.11. Хезмәт күрсәтүгә карата башка таләпләр

2.11.1. Хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Республика порталында урнаштырылган Хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон сурәтләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә расланган документларны һәм мәгълүматны Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) электрон рәвештә бирелгән Хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәүнең барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

4) Хезмәт күрсәтү сыйфатын Республика порталы ярдәмендә бәяләргә;

5) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазифаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә карарларына һәм гамәлләр кылуына ( кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Башкарма комитетның, шулай ук аның вазифа затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерергә.

2.11.2. Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада гариза бирү кирәклегеннән гайри гамәлгә ашырыла.

2.11.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне КФҮтә кабул итү буенча язылу (алга таба - язылу) Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Кабул итү өчен мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратып алына торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләге буенча);

кабул итү буенча теләгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән белешмәләр шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән кабул итү вакытыннан соң 15 минут үткәч килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында аңа мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылуны теләсә кайсы вакытта кире кагырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы аралыгын исәпләп чыгару өчен кирәк булган белешмәләр бирүдән тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.12. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.12.1. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар түбәндәгечә бүленә:

1) мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар ;

2) мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар .

2.12.2. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документ формалары турында белешмәләр әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

3.1. Административ процедуралар исемлеге

Хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
1) Хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;
2) ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;
3) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
4) мөрәҗәгать итүчегә Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.2. Ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;

3.2.1. Хезмәт күрсәтүне алу өчен «Ведомствоара электрон үзара бәйләнешнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрергә кирәк:

1) «Күчемсез милек объекты турында бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

2) «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгать юридик зат хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгать индивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла.

3.2.2. Хезмәт күрсәтүне алу өчен түбәндәге башка сервислар аша ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрәрергә кирәк:

1) «Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләренраслый торган документ» мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры» сервисы йә «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә, мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, 1 эш көненнән артык булмаган вакытта гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать , мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта,

«Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтүдәге рәсми мөрәҗәгатьнең статусы үзгәрүе турында түбәндәгечә хәбәр ителә:

4.1.1. Хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул ителгәнлеге турында;

4.1.2. Гариза һәм документлар җыелмасы каралганлыгы турында;

4.1.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру турында, шулай ук мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең бирелгән этабында башкарырга тиешле алдагы адымнар һәм гамәлләр турында, санап үтелгән ысулларның берсе белән :

1) смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
2) Бердәм портал ярдәмендә;
3) Республика порталы ярдәмендә;
4) башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

1 нче кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТЫЛМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы(http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты – Башкарма комитет;
5. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.

2 нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билге атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билге идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Реклама корылмасын урнаштыруга һәм аннан файдалануга рөхсәт | Физик зат | 1А |
| 2. | | Юридик зат | 2А |
| 3. | | Мөрәҗәгать итүче вәкиле | 3А |
| 1. | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм аннан файдалануга рөхсәтне гамәлдән чыгару турында карар | Физик затлар | 1Б |
| 2. | | Юридик затлар | 2Б |
| 3. | | Мөрәҗәгать итүче  вәкиле | 3Б |

3 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-3А, 1Б-3Б | шәхесне таныклый торган документ шәхесне таныклый торган документ (мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү шәхсән кабул иткәндә Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе гражданы паспортын я шәхесне таныклый торган башка документны күрсәтү юлы белән яисә 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән башкарылырга мөмкин) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 3А, 3Б | Мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
